# С Ы Й Ф А Т

Предметның билгесен белдереп,**нинди? кайсы? кайдагы?** сорауларына җавап бирүче мөстәкыйль сүз төркеме

**Тышта ак кар ява**

**Бу җөмләдә карның ак төстә булуы әйтелә. Бу җөмләдә без карның тик ак икәнен генә беләбез. Һәм бу сыйфатның гади дәрәҗәсе була**

**Ак, зәңгәр, матур, яшел, сары, чибәр, зур, кечкенә**

**Беренче шар икенчесеннән кызылрак**

Бу җөмләдә сыйфат шарның кызылрак икәнен хәбәр итә, ягъни аны икенче шар белән чагыштыра.

**Гади дәрәҗә+ рак, - рәк кушымчасы= чагыштыру дәрәҗәсе**

**Кызылрак, зәңгәррәк, олырак, кечкенәрәк, матуррак, озынрак**

**Бу алма кып – кызыл булып пешкән**

**Бу җөмләдә сыйфат алманың нык кызыл булуын, артыгыннан бигрәк кызаруын күрсәтә.**

1. Көчәйткеч кисәкчә(кып-,кап-зәп-, сап-,ямь-)+ гади дәрәҗә= артыклык дәрәҗәсе

2. Иң, үтә,дөм, җете кисәкчәләре + гади дәрәҗә = артыклык дәрәҗәсе

3. Сыйфатларның кабатлануы = артыклык дәрәҗәсе

Сап-сары,кап-кара, зәп-зәңгәр, ямь-яшел.
Иң матур, үтә чибәр, җете кызыл, дөм сукыр.
Кызылның кызылы, матурның матуры, сарының сарысы.

# Күлнең суы зәңгәрсу төстә иде

**Бу җөмләдә сыйфат күлнең зәңгәрдән ачыграк булуын күрсәтә, кимлек билгесен үсти.**

**Гади дәрәҗә+ -су, -гылт, -кылт, -келт, -кылтым, - келтем, -елҗем, -сыл кушымчалары = кимлек дәрәҗәсе**

Зәңгәрсу, кызгылт, ачкылт, яшькелт, ачкылтым, төчкелтем, күгелҗем, аксыл

ТӘМАМ!
Игътибарыгыз өчен
ЗУР РӘХМӘТ!!!